**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 маендагы 1490 номерлы карары**

**Казан шәһәре Авиатөзелеш районы администрациясе башлыгының 2004 елның 24 февралендәге 126 номерлы «Блочная урамындагы 3 номерлы торак йортка рөхсәтсез төзелгән янкорманы законлаштыру һәм җир кишәрлеген Е.С.Йосыпова милкенә бирү турында» карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 48 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон, «Авторы настоящего» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте гаризасы нигезендә, ачык сервитут билгеләнгән җәмәгатьчелек ихтыяҗлары булмау сәбәпле, карар бирәм:

1. Казан шәһәре Авиатөзелеш районы администрациясе башлыгының 2004 елның 24 февралендәге 126 номерлы «Блочная урамындагы 3 номерлы торак йортка рөхсәтсез төзелгән янкорманы законлаштыру һәм җир кишәрлеген Е.С.Йосыпова милкенә бирү турында» карарына, 2 пунктта «ремонт һәм блоклы корылмаларның гомуми стенасын куллану өчен 16,0 кв.м мәйданлы сервитут белән чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карар нигезендә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**